РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ МЭРЫ
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ МЭРЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2021 елның 10 ноябре

№ 10

«Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәрендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре мэрының 2021 елның 1 ноябрендәге 9 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

Татарстан Республикасында COVID-19 коронавирус инфекциясе таралуын чикләү буенча чараларны саклауны исәпкә алып һәм COVID-19 коронавирус инфекциясен профилактикалау буенча санитар-эпидемиологик кагыйдәләрне үтәү йөзеннән карар бирәм:

1. «Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәрендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре мэрының 2021 елның 1 ноябрендәге 9 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, мәгълүмати стендларда һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегенең «Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге» бүлекчәсендә урнаштырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев